# «Җиңү язы» бәйгесе

# НИГЕЗЛӘМӘ

**I Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге нигезләмә «Җиңү язы» бәйгесен (алга таба – Бәйге) оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Бәйгене гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» АҖнең «Салават күпере» журналы редакциясе филиалы» – «Сабантуй» журналы.

1.3. Бәйгенең максаты – Бөек Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итү уңаеннан укучыларда ватанпәрвәрлек, туган илгә мәхәббәт хисе тәрбияләү, балаларда сугыш һәм тыл ветераннарына хөрмәт хисе уяту, аларның кылган батырлыкларын барлау һәм мәңгеләштерү.

**II Бәйгене үткәрү шартлары һәм тәртибе**

2.1. Бәйге 2020 елның 3 нче апреленнән 15 нче апрельгә кадәр үткәрелә. Әлеге бәйгедә «Сабантуй» журналына язылучы гаиләләр катнаша ала.

2.2. Бәйге шартлары буенча, балалар Җиңү темасына рәсем ясый. Әлеге рәсемне («Җиңү язы» тамгасы белән) «Сабантуй» журналының sabantui@bk.ru электрон адресына җибәрә.

2.3. Бәйгедә 7 яшьтән алып 12 яшькә кадәр булган балалар катнаша ала.

2.4. Бәйгегә бары тик акварель яки гуашь ярдәмендә ясалган төсле рәсемнәр кабул ителә.

**III Таләпләр**

3.1. Катнашучылар гариза-анкета тутыра (1 кушымта).

3.2. Катнашучылар гариза-анкета һәм 2020 елның икенче яртыеллыгына «Сабантуй» журналына язылу турында квитанция күчемәсен яки фотосын sabantui@bk.ru адресына юллый.

**IV Йомгак ясау, бүләкләү**

4.1. Рәсемнәрне кабул итүнең соңгы көне: 2020 елның 15 нче апреле. Нәтиҗәләр ясау: 17 нче апрель, 2020 ел.

4.2. Эшләр редакция хезмәткәрләре тарафыннан бәяләнә. Бәйге нәтиҗәләре буенча җиңүчегә «Монополия» өстәл уены бүләк ителә. Иң уңышлы дип табылган рәсемнәр «Сабантуй» журналының май санында бастырыла. Барлык катнашучыларга да күрсәтелгән электрон адреска электрон сертификат җибәрелә.

4.3. Җиңүчеләрне бүләкләү вакыты һәм урыны, бәйгегә йомгак ясаганнан соң, 2020 елның май аенда www.sabantuyjournal.ru сайтында игълан ителәчәк.

***1 кушымта***

**«Җиңү язы» бәйгесендә катнашу өчен**

**гариза-анкета**

| | |
|---|---|
| Катнашучының исеме, фамилиясе, әтисенең исеме | |
| Катнашучының яше | |
| Адрес, телефон номеры, электрон адрес | |
| Җитәкчесенең исеме, фамилиясе | |

Әлеге гариза-анкетаны җибәрүем 27.07.2006 елның «Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык турында» 152 нче санлы Федераль законының 9 нчы маддәсе, 4 нчы бүлеге нигезендә, минем шәхси мәгълүматларымны тапшыру һәм эшкәртүгә ризалык бирүемне далилли.